# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА БҮЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

30 октябрь, 2019 ел　　　　　Яңа Бүләк авылы　　　　　№ 11

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Күктәк-Мирсәет авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Яңа Бүләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә

**КАРАР:**

1. 2019 елның 14 ноябренә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Күктәк-Мирсәет авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Яңа Бүләк авыл җирлеге Күктәк-Мирсәет авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сумм күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм анны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сумм күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Күктәк-Мирсәет авылы зиратына койма ясау һәм урнаштыру.

«ӘЙЕ»　　　　　«ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Күктәк-Мирсәет авылы, Һ.Такташ урам, 25йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы　　　　　М.С. Сәгытдинов